РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Простинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Прости авыл җирлеге
Советы

423553, Нижнекамский район,
с. Прости, ул. Школьная, 8

423553, Түбән Кама районы,
Прости авылы, Мэктэп урамы, 8

тел./факс (8555) 44-98-35, электронный адрес: Prostinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www. prostinskoe-sp.ru

## РЕШЕНИЕ КАРАР

от 17.12.2021 ел № 24

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Прости авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әлеге карарны халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Прости авыл җирлеге
башлыгы Д.А.Бадартинов

Прости авыл җирлеге
Советының
2021 елның 17 декабрендәге
24 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясында 9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү торган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;».

2. «Җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 38 статьясында 1 өлешнең 7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе катнашучысы - чит ил гражданлыгын туктату, чит ил дәүләте гражданлыгы (гражданлыкта булу) яисә тору кәгазе яки Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган чит ил гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;».

3. «Җирлек башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 44 статьясында:

а) 1 өлешнең 8 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе катнашучысы - чит ил гражданлыгын туктату, чит ил дәүләте гражданлыгы (гражданлыкта булу) яисә тору кәгазе яки Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган чит ил гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;».

б) 2 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа Җирлек башлыгы җирлек Советының якындагы утырышында мондый вәкаләтләре туктатылган көннән алты айдан да артмаган срокта сайлана.

Җирлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганнан соң алты ай узгач, Җирлек Советы утырышын Җирлек Советының яше буенча иң өлкән депутаты алып бара.».

4. «Башкарма комитет вәкаләтләре» 47 статьясында:

а) 1 пунктның 7 пунктчасындагы 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү торган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;»;

б) 3 өлешнең 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.».

5.«Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре эчтәлеге» 64.1 статьясындагы 2 пунктының 17 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.